РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**Красновидовского сельского Поселения Камско-Устьинского муниципального района**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**Красновидово авыл**

**БАШЛЫГЫ**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 18 ноябре** **№ 12**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә Антоновка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елның 29 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Антоновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Антоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан,1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум

күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорт;

шулай ук, карар кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы В.П.Оленин